| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«КУАКБАШСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«КУАКБАШ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 елның 27 октябре № 3

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Куакбаш авыл җирлегенең Куакбаш авылында гражданнарның үзара салым акчасын кертү һәм файдалану буенча гражданнар җыены үткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Куакбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 статьясы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы «Куакбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы КАРАР БИРДЕ:

1.Лениногорск муниципаль районы Куакбаш авыл җирлегенең Куакбаш авылында гражданнарның үзара салым акчасын кертү буенча гражданнар җыенын 2021 елның 20 ноябрендә 14 сәгать 00 минутта дип билгеләргә.

2.Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

2022 елда үзара салым кертүгә Лениногорск муниципаль районы Куакбаш авыл җирлегенең Куакбаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән, көндегге формада укучы студентлардан тыш, 300 сум күләмендә акча кертү һәм җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме:

2.1) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Куакбаш авылында (Совет ур., Ленин ур., М. Җәлил ур., һ. Такташ ур., К. Маркс ур., Маяковский ур., Тукай ур., Сәйдәш ур., Г. Исхакый ур., Яшьләр ур.) юлларны кардан чистарту;

2.2.) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызуны оештыру:

- Куакбаш авылында су линияләрен өзүне бетерү
- урам колонкаларын төзекләндерү.

«ӘЙЕ» «ЮК».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Куакбаш авылы, Карл Маркс урамы, 15 йорт адресы буенча урнашкан җирле үзидарә бинасында, Сходнево-Чертанлы авылы Ирек урамы, 5а буенча урнашкан авыл клубы, Чүте авылында Тынычлык урамы 8А буенча урнашкан авыл клубы бинасында урнашкан мәгълүмат стендларында, Лениногорск муниципаль районының рәсми Интернет-сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.r) урнаштырырга.

4. Әлеге карар басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

«Куакбаш авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Р.Р.Әхмәтҗанова